Татарская лингвокультурология: концепты духовного мира человека/ Р.Р. Замалетдинов и др. – Казань: ИПК «Бриг», 2012. – 300 с.
Nurieva, F.Sh. Literary Language of the Golden Horde: Norms and Variations// Life Science Journal. 2014. Vol. 10 (11). P. 713-717.

***Гыйләҗева Светлана Фәһимовна***
Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан

# ӘМИРХАН ЕНИКИ ТӘНКЫЙТЕНЕҢ ТЕМАТИКАСЫ ҺӘМ ЖАНР ТӨРЛЕЛЕГЕ

*В данной статье расценивается деятельность знаменитого татарского писателя Амирхана Еники в области татарской литературной критики. Дается описание такого вида критической мысли, как критика писателей, которая является самым распространенным видом татарской литературной критики. В статье выделена основная тематика и жанры критики Амирхана Еники.*

**Ключевые слова**: *Амирхан Еники, литературная критика, критика писателей, тематика, жанр.*

*This article contains the main idea of the writer's criticism, such as the type of the literature criticism, which is the most popular type of the Tatar literature criticism. Amirhan Eniki is the talantest writers of Tatar literature. Also he was the critic, which could say his opinion about literature and culture.*

**Key words:** *Amirhan Eniki, literature criticism, writer's criticism, thematic, genre.*

Бүгенге көндә татар әдәби тәнкыйте фән буларак формалашып җитте: аның предметы, бурыч-максатлары, әдәби тәнкыйтьнең төрләре, аның тарихи чорлары аерылып, өйрәнелә. Шул нисбәттән, тәнкыйтьтә профессиональ, язучы һәм укучы тәнкыйте аерым карала. Татар әдәби барышының үзенчәлекле ягы – ул язучы тәнкыйтенең популяр булуында. Әмирхан Еники тәнкыйди эшчәнлеге дә әдәби тәнкыйтьнең шушы төренә карый.

Әдипне киң җәмәгатьчелек күбрәк язучы буларак яхшы белә, әмма аның публицистика өлкәсендәге хезмәтләре никтер бәяләнеп бетми. Әдәбият фәнендәге шушы бушлыкны берникадәр тулыландыру максаты белән бүгенге көндә безнең тарафтан Әмирхан Еникинең тәнкыйди эшчәнлеге тирәнтенрәк өйрәнелә. Язучының тәнкыйди мәкаләләре тупланган өч китабы дөнья күргән: «Хәтердәге төеннәр» (1983) [1, 224], «Кояш баер алдыннан» (1996) [2, 192] һәм «Биектән карап торасым килә» (2009) [3, 215].

Билгеле, Еники профессиональ тәнкыйтьче түгел, әмма язучы тәнкыйте һәм профессиональ тәнкыйть арасында Кытай стенасы юк. Дөрес, укый-яза белеп, үз күңелдәгесен каләм белән кәгазьгә төшерергә теләүчеләр саны күп.

Әдәбият өлкәсендә кайнап яшәгән, әдәби барышны эченнән үк яхшы белгән, тоемлаган, талантлы язучының да башкаларга карата үз фикерен, теләк-киңәшләрен әйтергә хокукы бар. Алай гына да түгел, милли әдәбиятның һәм гомум сәнгатьнең алга китешен теләп, милләте өчен янып-көюче әдип моны эшләргә тиеш тә. Шуңа күрә Ә. Еникинең дә үзенең иҗатын тәнкыйди эшчәнлек белән үреп баруы табигый.

Профессиональ тәнкыйть үзенең академик характерда булуы белән аерылып торса, язучы тәнкыйтенә үтә субъективлык, шәхси башлангычның киң урын алуы, үзгә зәвыкка нигезләнү хас. Әдип теге яки бу әсәрнең үзенең әдәби-эстетик эзләнүләренә, шәхси иҗат тәҗрибәләренә нигезләнеп бәяли, мөнәсәбәтен белдерә. Шуңа күрә Ә. Еники язмаларында да көтелмәгән ассоциацияләр, бәйләнешләр, нәтиҗәләр урын алган.

Язучы үзенең бу төр мәкаләләрендә әдәби әсәрләргә әдәби-эстетик, әхлакый-фәлсәфи казанышларыннан чыгып бәя бирә; үз чорының әдәби барыш үзенчәлекләрен ача; заман биеклегеннән торып, үткән чор әдәбиятына бәя бирә; аерым шәхесләргә һәм аларның иҗатларына туктала.

«Кояш баер алдыннан» һәм «Биектән карап торасым килә...» тәнкыйди мәкаләләр тупланган җыентыкларында Ә.Еники күбрәк сәяси мәсьәләләргә карата үз фикерен белдерә. «Хәтердәге төеннәр» китабында аның әдәбият, сәнгатькә карата булган мөнәсәбәте ачык чагылыш тапкан, аерым бер истәлекләре урын алган. Шул рәвешле, тематик яктан язучы тәнкыйтен түбәндәге төрләргә төркемләштереп карый алабыз:

1) әдәбият нәзариясе мәсьәләләре, язучының иҗат портреты, аерым бер язучыларның әдәби әсәрләренә, китапларына карата әйтелгән фикерләр: «Нәкый Исәнбәт», «Безне ул өйрәтте» (Галимҗан Ибраһимов турында), «Шагыйрь ерак сәфәрдән кайтты» (Сәгыйть Сүнчәләй турында), «Әсәрнең теле турында», «...Йолдыз кеби» (Габдулла Тукай турында), «Безнең Фатих» (Фатих Хөсни турында), «Халык тормышы һәм әдәбият», «Дуслар белән бер сөйләшү», «Язу – намус эше» һ.б.

2) сәнгать мәсьәләләренә караган мәкаләләр, театр тәнкыйте: «Рәйхан», «Чын тормыш юлыннан», «Зәңгәр шәл», «Казан сөлгесе», «Фәридә Кудашева турында бер-ничә сүз», «Беренче карлыгачлар», «Ил кызы», «Кешелекле гүзәл талант», «Бәхет мәсьәләсе» һ.б.

3) истәлекләр: «Косогор заводы – Муса Җәлил – Ясная Поляна», «Чын кеше, чын иҗатчы», «Иң соңгы очрашу», «Хәтердәге төеннәр», «Очрашу һәм аерылышу», «Күңел түрендә» һ.б.

4) сәяси мәсьәләләргә карата әйтелгән фикерләр: «Казаннардан Мәскәү күренә», «Сабан туен без дә күрдек», «Бөреледәниләр бар», «Ипекәй», «Казан миңа да кадерле», «Иске белән яңа», «Безгә үлем явы килде», «Теләк», «Кысыр хәсрәт», «Язгы уйланулар», «Егылганны кыйнау кирәкме?» һ.б.

Ә. Еники тәнкыйтендә күбесенчә түбәндәге жанрлар очрый: мәкалә, рецензия, очерк, истәлекләр. Ул мөрәҗәгать иткән жанрлар арасында бүгенге көндә әдәбият галимнәре аерып чыгарган информатив, аналитик, әдәби-публицистик төрләрне дә күрергә мөмкин. Ә. Еникиның иҗтимагый-әхлакый позициясе, әдәби-эстетик һәм фәлсәфи карашлары, эстетик зәвегы һәм идеалы әдәби барышны бәяләвендә, стилендә, бәяләү формаларында хәлиткеч роль уйный. Аналитик жанрлардан Еники рецензияләр, әдәби күзәтүләр, проблемалы һәм теоретик характердагы мәкаләләргә яратып мөрәҗәгать иткәнлеген күрә алабыз. Аның «Нәкый Исәнбәт» юбилей мәкаләсе, «Халык тормышы һәм әдәбият» теоретик мәкаләсе, «Бәхет мәсьәләсе» проблемалы мәкаләсе шундыйлардан. Еникинең бу төрләргә караган әле бик күп мәкаләләре мәгълүм.

Ә. Еники – иҗади шәхес. Шуңа күрә дә аның әдәбият мәсьәләләренә карата үз мөнәсәбәтен белдергән мәкаләләр дә язуы табигый. Шундыйлар арасында аның «Язу – намус эше», «Дуслар белән бер сөйләшү» һ.б. мәкаләләре.

Әдәби-публицистик төрләрдән очерклар, аның бер төре – сәяхәтнамә-юлъязмалар, истәлекләрне дә Еники тәнкыйди максатларда файдалана. «Косого заводы – Муса Җәлил – Ясная поляна», «Шагыйрь ерак сәфәрдән кайтты», «Чын кеше, чын иҗатчы», «Очрашу һәм аерылышу», «Күңел түрендә», «Хәтердәге төеннәр» һ.б. мәкаләләре – шундыйлардан.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Ә. Еникинең әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә киң колачлы эшчәнлек алып барганын әйтә алабыз. Әдипнең тәнкыйте язучылар тәнкыйтенә карый, ул публицистик характерда. Ә. Еникинең тәнкыйди мәкаләләре рухи мирасыбызның, милли хәзинәбезнең бай катламын тәшкил итә.

**Кулланылган әдәбият**

Еники, Ә. Хәтердәге төеннәр: мәкаләләр, очерклар һәм истәлекләр / Әмирхан Еники. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983.-224 б.

Еники, Ә. Кояш баер алдыннан: публицистик мәкаләләр / Әмирхан Еники. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 192 б.

Еники, Ә. Биектән карап торасым килә...: Заманым һәм замандашларым турында / Әмирхан Еники. – Казан: Мәгариф, 2009. – 215 б.

Хатипов, Ф., Сверигин, Р. Яшәү мәгънәсе // – Мәгариф. – 2009. – №3. – Б.19-24.

***Гыймадиева Гөлүзә Ильясовна***

Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан

## ТӨРЕК-ТАТАР ӘДБИ-МӘДӘНИ БАГЛАНЫШЛАРЫ (Н. АГАЕВ МӘКАЛӘЛӘРЕ МИСАЛЫНДА)

*В данной статье говрится об особенностях развития турецко-татарских литературных межкультурных коммуникаций. Н. Агаев был од-*